**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге**

# КАРАР

**№ 6** **21 нче сентябрь 2020 нче ел.**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең аерым вәкаләтләрен тапшырырга.
2. Җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрен муниципаль район тарафыннан гамәлгә ашыру турында килешүне расларга (кушымта).
3. Әлеге карарны үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә муниципаль район тарафыннан җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында килешү төзергә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**Сәвәләй авыл җирлеге башлыгы** **П.С.Уразайкин**

Зәй муниципаль районы
Сәвәләй авыл җирлеге Советының
21.09. 2020 ел
6 номерлы карарына
кушымта.

Җирлекнең бюджет процессын оештыру буенча муниципаль район тарафыннан аерым вәкаләтләрне башкару турында

КИЛЕШҮ

Зәй муниципаль районы, Устав нигезендә эш итүче башлык Кәримов Разиф Гали улы исеменнән, алга таба «Муниципаль район» дип аталачак, һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге, Устав нигезендә эш итүче башлык Уразайкин Петр Сергеевич улы исеменнән, алга таба "Җирлек" дип аталачак, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

## 1 бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше нигезендә Җирлек
______________________________________________
(Җирлекнең исеме)
Муниципаль районга әлеге килешүдә билгеләнгән бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыра.

Бюджет процессын оештыру вәкаләтләрен башкарганда Яклар бюджет процессын оештырганда барлыкка килә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына нигезләнә.

Бюджет процессын оештыру буенча Муниципаль районның вәкаләтләре әлеге Килешү белән билгеләнә.

### 2 статья

Җирлек бюджеты акчалары (алга таба - бюджет) белән касса операцияләрен исәпкә алу Федераль казначылыкның территориаль органында муниципаль районның ачык финанс органы, казначылык счетларының шәхси счетларында 3231 номерлы «Җирле бюджетлар акчалары», 3232 номерлы «Җирле бюджетлар акчаларын алучыларның вакытлыча кулланылышына керә торган акчалар» казначылык счеты төренең кодлары белән башкарыла

## 2 бүлек. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

3 статья

Муниципаль район бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрне башкару процессында түбәндәге йөкләмәләрне үз өстенә ала:

- бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә, алучыларга, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) шәхси счетлар ачуны;

- алар карамагында булган бюджет акчаларын алучылар тарафыннан финанслануның иң чик күләмнәрен алу һәм бүлү буенча операциянең бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең, бүлүчеләрнең шәхси счетларында исәпкә алуны;

- бюджет акчаларын алучыларның шәхси счетларында финанслау күләмен, касса чыгымнарын исәпкә алуны;

- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторларының (администраторларының) тиешле шәхси счетларында финанслау күләмен, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча касса түләүләрен исәпкә алуны;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә, вакытлыча карамакка керә торган, бюджет акчаларын алучыларның тиешле шәхси счетларындагы средстволарны исәпкә алуны;

- бюджет акчаларын алучыларның шәхси счетларында бюджет һәм акча йөкләмәләрен исәпкә алуны;

- бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын исәпкә алуны, бюджет ассигнованиеләрен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә, алучыларга, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) бүлүне гамәлгә ашыруны;

- бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитларыннан яисә бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләреннән артмауны, шулай ук Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе кодына бюджет йөкләмәсе турында мәгълүматның туры килүен тикшереп торуны гамәлгә ашыруны;

- бюджет акчаларын алучыларның акча йөкләмәләрен түләүне санкцияләүне гамәлгә ашыруны;

- тиешле бюджет йөкләмәсен исәпкә кую турында акча йөкләмәсе турында мәгълүматның исәпкә куелуын контрольдә тотуны;

- акча йөкләмәсен түләү өчен эш итүдә күрсәтелгән мәгълүматның, акча йөкләмәсе турында мәгълүматның туры килүен тикшереп торуны;

- дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында каралган контрактлар реестрында муниципаль контракт турында белешмәләрнең туры килүен һәм муниципаль контракт, муниципаль контракт шартлары нигезендә барлыкка килгән бюджет йөкләмәсе, исәпкә алынган бюджет йөкләмәсе турында белешмәләр бирүне контрольдә тотуны;

- бюджет ассигнованиеләрен финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) тарафыннан бүленгән бюджет

ассигнованиеләренең артмавын һәм /яки бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча бүлеп бирелгән бюджет билгеләнешеннән һәм/яисә финанслау күләменнән финанслау күләмнәрен контрольдә тотуны;

- «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы 5 өлешендә каралган контрольне гамәлгә ашыруны;

- муниципаль районның финанс органы һәм җирлекнең финанс органы арасында мәгълүмат алмашу тәртибе һәм шартлары турында Регламентта каралганча (алга таба - Регламент; 1нче кушымта), Җирлекнең финанс органына, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бүлүчеләр, алучылар, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторлары) мәгълүматны формалаштыру һәм тапшыруны;

- бюджет акчаларын алучылар һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) йөкләмәсе буенча бюджеттан касса түләүләрен үткәрүне тәэмин итү өчен бюджет счетларында калган акчаларның мониторингын гамәлгә ашыруны;

- бюджет акчаларын түләтүне күздә тоткан башкарма документларны билгеләнгән тәртиптә башкаруны оештыруны;

- бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бүлүчеләр, алучыларның шәхси счетларында акча тоту буенча операцияләр башкаруны туктатып торуны;

- эчке муниципаль финанс контролен тормышка ашыруны;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бүлүчеләр, алучылар, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) шәхси счетларында чагылдырылган операцияләр буенча мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итүне;

- бюджет процессын оештыру буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыру барышында барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча Җирлек, бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә, алучыларга, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) консультацияләр бирүне.

4 статья

Муниципаль район түбәндәге хокукларга ия:

- Җирлектән, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бүлүчеләр, алучылар, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларыннан (администраторлары) билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән, регламент белән билгеләнгән түләү документларын алырга;

- Җирлек тарафыннан әлеге Килешүнең һәм Регламентның шартларын үтәүне таләп итәргә.

5 статья

Җирлек үз өстенә йөкләмә итеп ала:

- муниципаль районга җирлек, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бүлүчеләр, алучылар, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) тарафыннан билгеләнгән таләпләр

нигезендә рәсмиләштерелгән, регламент белән билгеләнгән түләү документларын бирүне;

- җирлек, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр, бүлүчеләр, алучылар, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары (администраторлары) тарафыннан әлеге килешү һәм регламентның үтәлешен;

- акча йөкләмәләрен акча средстволары белән ныгытуны тәэмин итү өчен оператив чаралар күрүне.

6 статья

Җирлек хокуклы:

- муниципаль район тарафыннан бюджет акчаларын баш бүлүчеләргә, бүлүчеләргә, алучыларга, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына (администраторларына) Регламентта билгеләнгән мәгълүматны үз вакытында бирүне таләп итәргә.

- муниципаль район тарафыннан әлеге килешү һәм регламент шартлары үтәлүне таләп итәргә.

## 3 бүлек. БАШКА ШАРТЛАР

7 статья

Муниципаль район җавап бирми:

- җирлекнең, баш администраторларның (администраторларның), бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең, бүлүчеләрнең, алучыларның һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларының (администраторларының) йөкләмәләре буенча;

- касса түләүләре үткәрү өчен казначылык счетында акча җитмәгән очракта, бюджет акчаларын алучыларның һәм башкарма документларның түләү документларын үтәүне тәэмин итү өчен бюджет акчаларын түләтүне күздә тота торган башкарма документлар өчен;

- түләү документларындагы мәгълүматларның һәм арифметик исәп-хисапларның дөреслеге өчен.

8 статья

Бюджет процессын оештыру буенча аерым вәкаләтләрне башкару муниципаль район тарафыннан түләүсез нигездә гамәлгә ашырыла.

9 статья

Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

## 4 бүлек. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ ВАКЫТЫ

10 статья

Килешү 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 5 елга төзелә.

Әлеге килешүнең гамәлдә булуы яклар килешүе буенча яисә якларның берсе тарафыннан язма хәбәрнамә буенча туктатылырга мөмкин, әгәр гамәлдәге килешүне туктату турында хәбәрнамә икенче якка агымдагы финанс елы тәмамланганчы 3 айдан да соңга калмыйча җибәрелгән булса.

5 бүлек. ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| ___________________________ | ___________________________ |
| ( Муниципаль районның исеме) | (Җирлекнең исеме) |
| Муниципаль район башлыгы __________ | Җирлек башлыгы |
| ___________________________ | ___________________________ |
| М.У. | М.У. |